| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2025 п.г.т.Алексеевское № 526

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 28.12.2024 ел, № 634 «2025-2029 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча Комплексды программаны раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә гражданнарның иминлеген тәэмин итү максатында

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 28.12.2024 № 634 карары белән расланган «2025-2029 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча Комплексды программа» га түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «2025 - 2029 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау чаралары программасын» «Мәгълүмат - телекоммуникация технологияләреннән файдаланып кылынган хокук бозуларга һәм җинаятьләргә каршы тору профилактикасы» 8 нче бүлек белән тулыландырырга (1 нче кушымта);

- программа паспортын «2025-2029 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау чаралары программасының максатчан индикаторлары» «Программаның максатларын һәм бурычларын еллар буенча бүлеп гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» бүлеге белән тулыландырырга (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Алексеевск муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
__03.12.2025 ел,__ № _526__
карарына 1 нче кушымта

## 2025-2029 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау чаралары программасы

| № т/б | Чара исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Җирле бюджет акчалары, бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән финанслау (мең сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел |
| **8** | **Мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып кылынган хокук бозуларга һәм җинаятьләргә каршы тору буенча профилактика** | | | | | | | |
| 1 | Җәмәгать урыннарында, рәсми сайтларда, социаль интернет челтәрләрендә мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып кылынган җинаятьләрне профилактикалау буенча мәгълүмат, шулай ук мошенниклыкның төп төрләре, аларны профилактикалау һәм бетерү ысуллары турында мәгълүмат урнаштыру | Алексеевск муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре (килештерү буенча) | 2025-2029 ел | - | - | - | - | - |
| 2 | Социаль челтәрләрдә, форумнарда, чатларда баланың аралашуын тикшереп тору кирәклеге турында ата-аналар белән аңлату эшләре алып бару | «ТР АМР мәгариф бүлеге » МКУ | 2025-2029 ел | - | - | - | - | - |
| 3 | Хокук бозуларны профилактикалау һәм мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып хокукка каршы гамәлләрне булдырмау мәсьәләләре буенча гомуми белем бирү оешмалары укучылары, яшьләр, халык һәм бигрәк тә пенсионерлар (хәвеф-хәтәр төркеме) белән аңлату эшләре үткәрү | Алексеевск районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килештерү буенча), «ТР АМР мәгариф бүлеге» МКУ, | 2025-2029 ел | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «АМР БК спорт бүлеге», «АМР БК яшьләр эшләре һәм туризм секторы», «АМР БК мәдәният бүлеге», АМРда «Движение Первых» ның җирле бүлеге, Алексеевск муниципаль районында ХМ һәм СЯМ ның СЯБ | | | | | | |
| 4 | Халыкка мәгълүмат-коммуникация технологияләрен һәм «цифрлы гигиена»буенча мәгълүмат-агарту чараларын кулланып кылына торган җинаятьләр турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү | «Заря» («Таң») газетасы редакциясе (килештерү буенча) | 2025-2029 ел | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
__03.12.2025 ел,__ № _526_
карарына 2 нче кушымта

**«2025-2029 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру» программасының максатчан индикаторлары**

| № т/б | Максатчан индикатор исеме | Үл.бер. | Максатчан индикатор булдыру алгоритмы | Максатчан индикаторның әһәмияте | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел |
| 1 | Мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып кылына торган теркәлгән җинаятьләр саны (урлау, мошенниклык, янап куркытып алу) | берәмлек | Җинаятьләрнең фактагы саны | < 1% | < 2% | < 2% | < 3% | < 4% |
| 2 | Җәмәгать урыннарында, рәсми сайтларда, социаль интернет челтәрләрендә мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып кылынган җинаятьләрне профилактикалау буенча мәгълүмат, шулай ук мошенниклыкның төп төрләре, аларны профилактикалау һәм булдырмау ысуллары турында мәгълүмат урнаштыру | берәмлек | Урнаштырылган мәгълүматның фактагы саны | > 10% | > 15% | > 15% | > 20% | > 20% |
| 3 | Мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып кылына торган җинаятьләрне профилактикалау буенча уздырылган чаралар саны | берәмлек | Үткәрелгән чараларның фактагы саны | > 10% | > 10% | > 10% | > 10% | > 10% |
| 4 | ММЧда урнаштырылган мәгълүмат саны | берәмлек | Урнаштырылган мәгълүматның фактагы саны | > 10% | > 10% | > 10% | > 10% | > 10% |